Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

2 октябрь, 2024 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 144 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Керәшен Сәрдәсе авылында үзара салым кертү буенча ике этапта гражданнар җыены үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 25 октябрендә 12 сәгать 00 минутта Совет урамы, 44а йорты янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Татарстан, Совет урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 25 октябрендә 13 сәгать 00 минутта Гагарин урамы, 135 йорты янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Болын, Гагарин һәм Яшьләр урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Керәшен Сәрдәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2.Көлкәмәр авылында 2024 елның 26 октябрендә Мәктәп урамындагы Бөек Ватан сугышының һәлак булган сугышчыларына куелган һәйкәл янында гражданнар җыены үткәрергә.

«Сез 2025 елда Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Көлкәмәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр).

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов